Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Сәрән авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

17 апрель 2023 ел №3

Әлмәт муниципаль районы Сәрән авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Сәрән авыл башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2011 елның 1 сентябрндагы 12 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында» 2021 елның 12 маендагы 55нче номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карары, 2022 елның 1 мартыннан кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы килешү нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 10 апрелендәге 02-08-01/175 номерлы протестын карап

Сәрән авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Сәрән авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Сәрән авыл башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2011 елның 1 сентябрндагы 12 номерлы карарының үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Чуаш Сәрәне авылы, Үзәк урамы, 34а йорт, Рус Сәрәне авылы, Үзәк урам, 15а йорт, Кителга авылы, Совет урамы, 8а йорт торак пункт территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сәрән авыл башкарма
комитеты җитәкчесе Д.А.Севастьянов